Пәнҗешәмбе, 09 Апрель 2015 14:14

# Саранскидагы стадионны да татарстанлылар төзи (ФОТО, ВИДЕО)



**“Казан” җитештерү-төзелеш берләшмәсе моңа кадәр масштаблы спорт объектларын төзүдә алдынгылыгын күрсәтте. Ул Самар һәм Саранск шәһәрләрендәге спорт объектларын төзү тендерын да отты. 2018 елга төзелеп бетшчшк Самар стадионы турында инде [язган] идек. Мордовия башкаласы Саранскида футбол стадионын төзү дә – татарстанлылар җилкәсендә.**

Бүген Саранскиның Волгоградская урамында тагын өч елдан 45 мең урынлык футбол стадионы була димәссең дә. Әлегә монда эш тулы куәтенә кайный. Ә булачак спорт объекты турында хәзергә постаментка урнаштырылган зур футбол тубы гына әйтеп тора.

**Сувайлар “Казан-Арена”ныкыннан да биегрәк**

Бу стадион төзү планнары инде шактыйдан булган. Тик дөнья чемпионаты уңаеннан, аны зурырак итеп ясарга карар кылынган. Самар стадионыннан аермалы буларак, Саранскидагы бу спорт объектының 30 мең урыны, монолиттан төзелеп, чемпионаттан соң даими рәвештә кулланыла торган булачак. Ә калган 15 мең урыны җыелма конструкция ярдәмендә ясала. Ягъни 2018 елгы вакыйгадан соң ул өлеше кулланмаячак.

- Самар һәм Саранскидагы стадионнар тышкы яктан бер-берсенә охшамаган. Мордовия башкаласындагысы көймә рәвешендә төзелә. Бинаның алгы ягы, төсе нинди булуы турында карар быелның июлендә кабул ителәчәк, – дип белдерде журналистларга “Казан” җитештерү-төзелеш берләшмәсе генераль директоры урынбасары **Леонид Щупальцев**.



Объектның проект-смета документларының вакытында тапшырылмавы төзелеш процессын тоткарлый икән. Леонид Щупальцев белдергәнчә, эш күләме, аның куәтлелеге аларга бик бәйле. Футбол стадионының Инсар елгасы тугаенда урнашуы төзелешкә комачауламасын өчен стадион 4,5 метрга күтәртелгән. Шул сәбәпле, “Казан-Арена”да сувайларның биеклеге 12 метр булса, Сарански алар 17 метр икән.

**Татарстан эшчеләренә – уңай шартлар**

Бу спорт объектын төзү узган елның октябрь аенда гына башланган. Апрель ахырына кадәр төзелеш шәһәрчеге – офис корылмалары, торак модульләр ясалачак. Без килгәндә, эшчеләр нигез чокырларын казу, сувай суга, фундамент салу эшләрен башкара иде. Бүгенгә фундамент салу инде 30 процентка башкарылган, 9400 сувайның 3150се сугылган. Июньдә аларны сугуны тәмамлап, ел ахырына стадионның монолит эшләрен башкарып чыгарга ниятли эшчеләр.



Эшчеләр арасында Мордовия халкы белән беррәттән татарстанлылар да күп. 42 берәмлек техниканың барысы да – безнең республикадан. Эш күләменең артуы белән техника саны да артачак. Бүген стадионда 300 кеше хезмәт куя. Киләчәктә аларның саны 970 кешегә җитәчәк. Бүген эшчеләрнең 50 проценты җирле халык булса, 65 кеше Татарстаннан килеп хезмәт куя.

Татарстанның Әлки районыннан Илнар Сафинның монда йөк төяү-бушату җайланмасы машинисты булып эшләвенә өч ай икән. Тимер аты ярдәмендә кыш көне стадион территориясеннән кар чыгарса, хәзер ком, туфрак төи, стадионда төрле материаллар ташый. Илнарның хатыны белән баласы – Казанда яши. Ул гаиләсе янына ике атна саен кайтып йөри. Хезмәт хакына килгәндә, Илнар елмаеп: "Ипи-майга җитә", – дип җавап бирде. Татарстаннан килгән эшчеләргә торак та бүлеп бирелгән, алар бөтен уңайлыклары булган фатирларда тора.



Казаннан килгән Эдуард Бәдретдинов, сувай сугучы буларак, гыйнвардан хезмәт куя. 20 көнгә якын эшләп, бер атнага Казанга кайта. Эдуардны да Казанда гаиләсе сагынып көтеп тора.

- Эштә вак-төяк проблемаларсыз булмый инде. Ләкин аларны шунда ук чишәргә тырышабыз, – ди ул. – Техника шундый нәрсә бит инде, ватылырга да мөмкин. Шуңа күрә алга таба эш барсын өчен аларны вакытында төзәтәбез. Шунысын әйтергә кирәк: бу җирлектә елгалар күп. Футбол стадионы фундаменты нык булсын өчен, монда сувай сугу аеруча мөһим.




Мордовия халкы үзләрендә 2018 елдагы футбол буенча дөнья чемпионатына стадион төзелгәне турында яхшы хәбәрдар икән. Шунысын да әйтеп узарга кирәк: футбол стадионы шәһәр эчендә урнашкан. Шул сәбәпле, монда килергә уңайлы булачак. Саранскидагы спорт объектлары бер тирәдә урнашкан. Мәсәлән, төзелеп килә торган стадионнан Су спорты төрләре сарае да ерак түгел.

Кабаттан төзүчеләргә әйләнеп кайтсак, “Казан” җитештерү-төзелеш берләшмәсенең тәҗрибәсендә “Казан-Арена”, Самардагы футбол стадионыннан кала, Саранскидагысы –

өченче зур футбол стадионы. Безнең төзүчеләрнең даны чит төбәкләрдә дә таралу без, татарстанлылар өчен, куаныч кына түгел, олы горурлык та әле. Шуңа стадион төзүчеләренә армый-талмый эшләргә теләп калабыз.

**Алинә МИННЕВӘЛИЕВА, автор видео һәм фотолары**

Укылган **174** мәртәбә

## 1 Фикер

Дүшәмбе, 13 Апрель 2015 11:13 **юсупова гулюса** язган

Фикер белдерү

Саумысыгыз.был Эш Мордовия республикасына кераме или кайсы якта була ул?а сезда Эш бармы,юкмы?

Шикаять белдерү